КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 21 декабрь г.Казань № б-2760

Татарстан Республикасында хайваннарның котыру авыруы белән авыру буенча эпизоотия хәлен яхшырту, әлеге авыруның авырган хайваннардан кешегә күчүен булдырмау максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында котыру авыруы белән авыруны профилактикалау чараларының комплекслы планын (алга таба – План) расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына Планның үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән кирәкле чаралар күрергә, шулай ук Кеше хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенә, «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына – әлеге чаралар күрүне тәкъдим итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021ел, 21 декабрь, б-2760 нчы
карары белән расланды

2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында
котыру авыруы белән авыруны профилактикалау чараларының
комплексны планы

| Т/с | Чаралар исеме | Үтәү сроклары | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | 2022 – 2026 елларга республика шәһәрләрендә һәм районнарында котыру авыруы белән авыруны профилактикалау чараларының комплексны планнарын эшләү һәм раслау | 2022 ел | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 2. | Аерым ведомстволарга караган район һәм шәһәр бүлекчәләре җитәкчеләренең 2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында котыру авыруы белән авыруны профилактикалау чараларының комплексны планнарын үтәү эше турында тыңлау | ел саен | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 3. | Татарстан Республикасының дәүләт ветеринария хезмәте, сәламәтлек саклау учреждениеләре, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе һәм «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе арасында эпизоотиягә каршы һәм | даими | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | эпидемиягә каршы вакытлы чаралар күрү максаты белән кешеләр һәм хайваннар арасында котыру авыруы белән авыру очраклары турында мәгълүмат алмашу | | сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча), Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы |
| 4. | Республика шәһәрләрендә һәм районнарында, хайванны теркәүгә алу турында таныклык биреп, хезмәт итә, саклый, аулый торган, йорт этләрен теркәүгә алу һәм аларга котыру авыруына каршы вакцинация ясау | даими | Татарстан Республикасы җирле үзидарәнең башкарма органнары җитәкчеләре (килешү буенча), район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре, хайваннар хуҗалары (килешү буенча) |
| 5. | Кыргый ерткыч җәнлекләр яши торган урыннарда вакциналы җимнәр куеп, аларга котыру авыруына каршы вакцинация ясау | ел саен яз һәм көз | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |
| 6. | Зоологик фаразны исәпкә алып, эпизоотиягә кадәрге чорда кыргый ерткыч җәнлекләр санын киметү буенча чаралар күрү | ел саен | Татарстан Республикасы җирле үзидарәнең башкарма органнары җитәкчеләре (килешү буенча), Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |
| 7. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибе нигезендә Татарстан Республикасында хуҗалары булмаган | даими | Татарстан Республикасы җирле үзидарәнең башкарма органнары җитәкчеләре (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | хайваннар санын аларны тотып алу, вакытлыча карап тоту пунктларында (приютларда) карап тоту һәм элеккеге яшәү урыннарына кире кайтару юлы белән җайга салу эшен тәэмин итү | | |
| 8. | Хуҗалары булмаган хайваннарны тотып алу, аларны стерилизацияләү һәм кастрацияләү, шулай ук элеккеге яшәү урыннарына кайтару чараларын гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган оешмалар (индивидуаль эшмәкәрләр яки юридик затлар) белән шартнамәләр төзү эшләрен оештыру | даими | Татарстан Республикасы җирле үзидарәнең башкарма органнары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 9. | Авыл хуҗалыгы җирләрендә тычкансыман кимерүчеләрне бетерү чараларын методик яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыру | даими | «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы (килешү буенча) |
| 10. | Көз һәм яз айларында чистартылган территорияләрдә тычкансыман кимерүчеләргә каршы профилактик дератизация чараларын тәэмин итү (торак пунктларны барьерлы дератизацияләү) | даими | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 11. | Территорияне чүпләп бетерүне булдырмау, каты көнкүреш калдыкларын җыю контейнерларын тиешенчә карап тоту өлешендә торак пунктларны төзекләндерүне тәэмин итү; каты көнкүреш калдыкларын үз вакытында чыгару, подвал урыннарын карап тоту буенча аларга хайваннарның үтеп керүенә мөмкинлек бирә торган шартларны булдырмый торган санитария-эпидемиология таләпләрен үтәү | даими | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары (килешү буенча), торак фондына хезмәт күрсәтә торган идарә итүче компанияләр, торак милекчеләре ширкәтләре рәисләре, торак-төзелеш кооперативлары (килешү буенча) |
| 12. | Йорт ерткыч һәм авыл хуҗалыгы хайваннарына котыру авыруына каршы вакцинация ясауны тәэмин итү | даими | район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре, Татарстан Республикасы җирле үзидарәнең башкарма органнары җитәкчеләре (килешү буенча), хайваннар хуҗалары (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 13. | Кешеләрне, авыл хуҗалыгы һәм йорт хайваннарын кыргый ерткыч җәнлекләр, этләр, мәчеләр һәм башка хайваннар тешләгән һәр очрагы яки котыру авыруы белән авыруга шик булу турында сәламәтлек саклау органнарына, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы бүлекчәләренә хәбәр бирү | ачыклануга карап | район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре |
| 14. | Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Котыру авыруы чыганаклары таралуны булдырмауга һәм аларны бетерүгә юнәлдерелгән профилактика, диагностика, чикләү чараларын һәм бүтән чараларны гамәлгә ашыру буенча ветеринария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 25 ноябрендәге 705 номерлы боерыгы нигезендә кешеләргә тешләп һәм башка зыяннар китергән этләрне, песиләрне һәм башка хайваннарны үз вакытында изоляцияләүне һәм 14 көн эчендә күзәтеп торуны тәэмин итү | ачыклануга карап | район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре, хайваннар хуҗалары (килешү буенча) |
| 15. | Котыру авыруы белән авыруга шик булган хайваннардан алынган биоматериалларга лаборатория тикшеренүләрен үткәрү | беренче тәүлек эчендә | район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре |
| 16. | Кыргый хайваннарның гадәти булмаган тотышы яки аларның үлеме очраклары турында дәүләт ветеринария хезмәтенә, сәламәтлек саклау органнарына хәбәр итү | ачыклануга карап | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары (килешү буенча), Татарстан Республикасы җирле үзидарәнең башкарма органнары җитәкчеләре (килешү буенча), Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |
| 17. | Авыру чыганагы чикләрен билгеләп, сәбәпләрен ачыклап, эшләнгән чаралар планы нигезендә инфекция чыганагын бетерү буенча ашыгыч чаралар күреп, хайваннар яки кешеләр арасында котыру авыруы белән | ачыклануга карап | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | авыруның һәр очрагына эпизоотология-эпидемиология тикшерүен үткәрү | | күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча), «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча) |
| 18. | Халыкка антирабик ярдәм күрсәтүче медицина оешмаларын антирабик препаратларның (вакциналар, иммуноглобулиннарның) кимеми торган запасы белән тәэмин итү буенча чаралар күрү | ел саен | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы |
| 19. | Һөнәри эшчәнлеге котыру авыруы вирусын йоктыру рискына бәйле затларны Татарстан Республикасы бюджетыннан эпидемия күрсәткечләре буенча профилактик прививкалар үткәрүгә бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән профилактик иммунизацияләүне оештыру | даими | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы медицина оешмалары (килешү буенча), оешмалар (килешү буенча), Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 20. | Котыру авыруы вирусын йоктыру рискына дучар булган затларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру, гамәлдәге документлар нигезендә дәвалау-профилактикалау иммунизациясе курсын үткәрү | даими | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы медицина оешмалары (килешү буенча) |
| 21. | Котыру авыруы белән авыру буенча имин булмаган шәһәрләрдә һәм районнарда экология хезмәте, урман хуҗалыгы хезмәткәрләре, аучылык белгечләре белән күрсәтмә бирә торган киңәшмәләр үткәрү | ел саен | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 22. | Сукбай хайваннарны тотып алу буенча яңа формалаштырыла торган бригадалар хезмәткәрләре белән күрсәтмә бирә торган киңәшмәләр үткәрү | ел саен | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары (килешү буенча), район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча), Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 23. | Хайваннардан зыян күргән затларга антирабик ярдәм күрсәтү буенча медицина хезмәткәрләре белән укыту семинарларын оештыру һәм үткәрү | ел саен | Татарстан Республикасы медицина оешмалары (килешү буенча), Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 24. | Квалификация категориясе бирүгә аттестация үткәргәндә медицина хезмәткәрләренең, ветеринария табибларының котыру авыруын профилактикалау һәм аңа каршы көрәшү мәсьәләләре буенча белем дәрәҗәсен тикшерүне оештыру | ел саен | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе |

---